

# Гайсә Христос безнең коткаручыбыз

**« Чөнки күк астында кешеләргә бирелгән, безне коткара алачак башка һичбер исем юк ». Ап. Эш. 4:12**

Тәуратта (Библияде) халкы Аның сүзенә буйсынырга теләмәгән шәһәрләр өстеннән Ходай хөкеме турында сөйләнә (Матф. 10:15, 11:22-24, Марк. 6:11, Лук.10:12-14). Шулай ук син яшәгән шәһәр халкына да, Ходайга сәҗдә итүчеләр сөйләгән Сүзге ничек караганлыклары хакында, Ходайга хисап бирергә туры киләчәк.

**Коткаручы бер генә**

Кадерле дустым, син котылганмы? Котылу турында Библия тантаналы рәвештә хәбер итә. Котылуны кешеләр уйлап чыгармаган. Мин моннан 20 ел элек христиан булдым, һәм әле хәзергә чаклы күп кешеләрнең Ходайның котылу турындагы хәбәрен аңламаганнарын күрәм.

Беренче чиратта, кеше Ходайның берлегенә һәм хаклыгына һәм Аны эзләүчеләргә бирүенә инанырга тиеш. Җанны Ходай гына коткара ала Аның исеме Рабби Гайсә Христос, бу турыда Библиядә сөйләнә.

Апостолларның Эшләрендә 4:12 без болай дип укыйбыз: «Чөнки күк астында кешеләргә бирелгән, безне коткара алачак башка һичбер исем юк ». Тулысынча үзенең тормышын Гайсә Христоска ышанып, кеше котылуны бушка ала. Мәңгелек тормыш алу өчен, син берни де эшли алмыйсың. Ышаныч — бу иман. Иман акылдан түгел, бәлки йөрәктән чыгырга тиеш. Син ничек яратасың һәм үзеңнең хатыныңа яки иреңә ышанасың иөрәгең яки акылың беләнме?

Платон, Аристотель, Эйнштейн бөек акыл ияләре булганнар, ләкин авыру, кайгы, ачлык, үлем кебек тормыш проблемаларын да хәл итә алмаганнар, мәңгелек тормыш серләренә үтеп керү турында әйтәсе дә юк. Безнең алга бу барлык проблемаларның җирдәге тормышта басасын Ходай белде һәм, шуңа күрә,

Үзенең Сүзендә бу сорауларга җавап бирде.

**Барысы да гөнаһ кылдылар**

Синең кайчан да булса, гөнаһ кылганың бармы? Бер генә тапкыр булса да? Бер тапкыр алдаштың яки урладың? «Барысы да гөнаһ кылдылар һәм Ходайның данынннан мәхрүм калдылар», дип әйтергә бу җитә (Рим. 3:23). Син гөнаһларыңнан котылу чарасына һәм гөнаһларыңны кичерүгә Гайсә Христоска иман аша ирешә аласың. Коткарылмаган гөнаһлы үз гөнаһ-ларында үлә һәм Кук Патшалыгына керә алмый, чөнки шулай язылган:«һәрбер саф булмаган Кук Патшалыгына керә алмый». Гөнаһлардан ничек арынырга соң?

Син көн саен гөнаһ кыласың һәм йөгең гел авырая бара. «Нәрсә эшләргә?» — дип сорыйсың син. Изге Инҗилдә Матф. 11:28 без бу сорауга мондый җавап табабыз: «Барлык тырышып эшлеүчеләр һәм йөкләре авыр булганнар, Миңа килегез һәм Мин сезне тынычландырырмын». Кешеләр арасында мондый сүзне әйтә алырлык кемне дә булса беләсеңме соң? Әлбәттә, юк! Болай дип Гайсә Христос кына әйтә алган!

Безнең тамырларыбызда нәсел башлыгы Адәмнең каны ага. Без гөнаһ эчендә туганбыз. Библия бу турыда Римлыларга хатта 5:12 болай ди: «Ничек гөнаһ бер кеше булып дөньяга керде һәм гөнаһ белән — үлем, шулай ук, үлем барлык кешеләргә күчте, чөнки аңарда барысы да гөнаһ кылдылар». Хәзер син үзеңнең гөнаһлылыгын һәм үзеңнең үләргә тиешлелеген турында беләсең.

**Гөнаһның проблемаларын хәл итү**

Гайсә Христосның яралгысы гадәти булмаган юл белән барлыкка килде.

Инҗилдә Матф. 1:20 болай әйтелгән: «чөнки аның карынындагы Изге Рухтандыр». Бу—Гайсә Христос— Ходай Улы дигән сүз. Аның тамырларында илаһи кан ага. Библия әйтә: «Кан коелмыйча кичерү булмый ». (Евр. 9:33). Безнең кан шундый бозылган, шуңа күрә, гөнаһларызны юу өчен коела алмый. Бары тик Христосның коелган каны гына безне гөнаһлардан юып чистарта, чөнки Ул гөнаһсыз, һәм Көнчыгыш Көнбатыштан ерак булган кебек, Ул бездән безнәң гөнаһларыбызны ерагайтты. Ходай әйтте, Ул беркайчан да безнең гөнаһларыбызны искә алмас. Син бу яхшы хәбәрне кабул итергә телисеңме?

**Бердәнбер гөнаһ**

Кадерле дустым! Кешеләр җәһәннәмгә гөнаһ кылганнары өчен түгел, ә бәлки аларның гөнаһлары өчен тәредә үлгән Гайсә Христосны кире какканнары өчен баралар. Библия сөйли: «Аңа сәждә итүчегә хөкем юк, ә сәждә итмәүче инде хөкем ителде, чөнки ул Ходайның бердәнбер Улының исеменә иман китермәде» (Яхъя 3:18). Ходай белә, син гөнаһлы кеше, ләкин Ул сине ярата һәм синең өчен үлде. Рухны коткару — кеше һәм Ходай арасында табигый булмаган күренеш. Христоска ышан, Аны үзеңнең йөрәгеңә шәхси Коткаручың итеп кабул кыл һәм Ходайга мондый дога белән мөрәҗәгать ит: «Раббым, Мин Синең алдында үземнең гаебемне таныйм, һәм Синең минем өчен үлүеңә ышанам мин Сине шәхси Коткаручы итеп кабул итем һәм тулысынча Сиңа ышанам, коткар мине!»

«Ә Үзен кабул итүчеләргә Ул Ходай балалары булырга хокук бирде» (Яхъя 1:12).

**FELLOWSHIP TRACT LEAGUE**
P.O. BOX 164 • LEBANON, OH 45036
www.fellowshiptractleague.org © Tract 3560 (Tatar)
All tracts free as the Lord provides. Not to be sold.